ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

К А Р А Р

12.07. 2019 № 125

Федераль һәм Республика законнарына һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль норматив хокукый актларга кертелгән үзгәрешләргә мониторинг үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл жирлеге җирле үзидарә органнарының Федераль һәм Республика законнарына һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль норматив хокукый актларга кертелгән үзгәрешләргә мониторинг үткәрү эшен камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Федераль һәм Республика законнарына һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль норматив хокукый актларга кертелгән үзгәрешләргә мониторинг үткәрү турындагы Нигезләмәне расларга.

2. Күрсәтелгән нигезләмәне үтәү өчен җаваплы зат итеп Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге секретаре Зиннәтуллина Гүзәлия Мөнир кызын билгеләргә;

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге секретаре Зиннәтуллина Гүзәлия Мөнир кызының вазифа инструкциясенә тиешле үзгәрешләр кертергә;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат интернет порталы http://pravo.tatarstan.ru / челтәрендә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтының Камай авыл җирлеге бүлегендә бастырып чыгарырга

5 Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Камай авыл җирлеге Советы рәисе И.И.Әһлиева

КУШЫМТА
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге Советының
2019 ел 12 июлендәге
125 номерлы карарына

**Федераль һәм Республика законнарына һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль норматив хокукый актларга кертелгән үзгәрешләргә мониторинг үткәрү турындагы нигезләмә.**

I. Гомуми нигезләмәләр.

1. Федераль һәм Республика законнарына, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына кертелгән үзгәрешләргә мониторинг (алга таба – мониторинг, муниципаль актлар, җирле үзидарә органнары) - муниципаль актларны кабул итүне (бастырып чыгаруны) ,үзгәртү яки үз көчен югалткан дип тануны (гамәлдән чыгаруны) тәэмин итү өчен үз вәкаләтләре чикләрендә җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгълүмат җыю, гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләү буенча системалы, комплекслы һәм планлы эшчәнлекне күздә тота.

2. Мониторинг җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә.

3. Җирле үзидарә органнары мониторинг үткәргәндә Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге һәм башка җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итәләр.

4. Мониторинг үткәрү өчен җирле үзидарә органнарында җаваплы затлар билгеләнә.

5. Мониторинг үткәрүнең максаты булып түбәндәгеләр торалар:

федераль һәм республика законнарына туры китерү максатларында муниципаль актларны кабул итүгә, үзгәртүгә яки үз көчләрен югалткан дип тануга булган ихтыяҗны ачыклау;

муниципаль актларда коллизияләрне, каршылыкларны, җитешсезлекләрне бетерү, хокукый җайга салуда кабатлануны бетерү;

җирле үзидарә органнарының норматив хокукый базасын системалаштыруны тәэмин итү;

муниципаль актларда коррупциоген факторларны ачыклау;

кирәк булмаган (актуальлеген югалткан) яки практикада кулланылмый торган муниципаль актлар яисә аларның аерым нигезләмәләрен (нормаларын) ачыклау;

хокук куллануның нәтиҗәлелеген арттыру;

муниципаль актларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген киметүче факторларны ачыклау;

муниципаль актларның үтәлешен тиешле җирле үзидарә органнары бүлекчәләре тарафыннан тикшереп торуны гамәлгә ашыруга булышлык күрсәтү;

норматив хокукый актлар иҗат итү процессын камилләштерү буенча

тәкъдимнәр эшләү.

6. Мониторинг түбәндәге законнарга һәм норматив хокукый актларга кертелгән үзгәрешләрне җыюны, гомумиләштерүне, анализлауны һәм бәяләүне үз эченә ала:

федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка закон актлары;

Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары, башка федераль дәрәҗәдәге законлы норматив хокукый актлар;

Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары;

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Уставына, муниципаль актларга.

7. Мониторинг үткәрү нигезләре булып түбәндәгеләр торалар:

федераль һәм республика законнары актларына үзгәрешләр кертү;

хокукый җайга салуның билгеле бер өлкәсендә муниципаль актларны куллануны анализлау;

прокуратура органнары мәгълүматы;

массакүләм мәгълүмат чараларының муниципаль актларның житешсезлекләре яки аларны камилләштерүнең кирәклеге турында мәгълүматы;

муниципаль актларның камил булмавы турында гражданнарның, юридик затларның, шул исәптән җәмәгать, фәнни, хокук саклау һәм башка оешмаларның, индивидуаль эшкуарларның, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының мөрәҗәгатьләре, шул исәптән:

Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертелгән муниципаль актларга карата Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан үткәрелгән Хокукый экспертиза бәяләмәләре;

Муниципаль актларга билгеләнгән тәртиптә аны үткәрүгә вәкаләтле затлар тарафыннан әзерләнгән коррупциягә каршы экспертиза бәяләмәләре;

Җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә торган конференция, семинарлар, халык тыңлаулары, иҗтимагый фикер алышулар һәм башка чараларның йомгаклау документлары.

## II. Мониторингны үткәрү тәртибе.

8. Җирле үзидарә органнары үзләренең компетенциясендәге мәсьәләләр буенча әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән җаваплы затлар белән үзара бәйләнештә мониторинг үткәрәләр.

Мониторинг уздыру максатларында эш төркемнәре төзелергә, киңәшмәләр, консультацияләр үткәрелергә, кирәкле мәгълүмат соратып алынырга, Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләре, Россия Федерациясе субъектлары тәҗрибәсен өйрәнергә, башка эш формалары кулланылырга мөмкин.

9. Мониторинг түбәндәге актларга анализ ясау ярдәмендә башкарыла:

әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән актлар;

федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге норматив хокукый актларга дәгъва белдерү турында эшләр буенча суд актлары (суд практикасы);

прокурор реакциясе актлары.

10. Җирле үзидарә органнарының норматив базасына мониторинг үткәрү, анализлауны гамәлгә ашыру, шулай ук мониторинг йомгаклары буенча үткәрелгән норматив хокукый актлар иҗат итү эше нәтиҗәләрен теркәү максатларында, җирле үзидарә органнарында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының "Муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын оештыру һәм алып бару тәртибе турында" карары нигезендә алып барыла торган муниципаль норматив хокукый актлар реестрлары кулланыла.

11. Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимизацияләү өчен мәгълүмати системаларның автоматлаштырылган сервислары (аларның операторлары белән контрактлар, килешүләр төзү мөмкин булган очракта) кулланыла:

«Гарант " мәгълүмат системасында закон һәм башка норматив хокукый актларга контрольгә куелган үзгәрешләр турында мәгълүмат керү»;

"Гарант " мәгълүмат системасының хокукый җайга салу өлкәләре буенча яңалыклар тасмалары тарафыннан мәгълүмат керү»;

«Кодекс» мәгълүмат компаниясенең «Региональ законнар аналитикасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы буенча муниципаль актларның законнар җыелмасына туры килмәүләре турында мәгълүмат алынуы.

Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимальләштерү максатларында башка мәгълүмат системалары сервислары кулланыла ала.

12. Муниципаль хокукый актларны кабул итүне (бастырып чыгаруны) тәэмин итү, үзгәртү яисә үз көчләрен югалткан дип тану өчен мониторингны гамәлгә ашырганда, әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән анализ белән беррәттән, муниципаль хокукый актларны түбәндәге критерийлар буенча куллану практикасы турында мәгълүмат гомумиләштерелә һәм бәяләнә:

кеше һәм гражданның гарантияләнгән хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү;

муниципаль актларны кабул итү (бастырып чыгару) зарурлыгы билгеләнгән зуррак юридик көчнең норматив хокукый актлары булу;

муниципаль акт чыгарганда җирле үзидарә органы компетенциясе чикләрен үтәү;

муниципаль актта коррупциоген факторлар булу;

иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуда тулы булу;

хокук нормалары коллизиясе;

юридик-техник характердагы хаталар булу;

муниципаль акт нигезләмәләренең аны кулланганда мәгънәсен бозу;

муниципаль хокукый актны кулланганда хокуксыз яисә нигезсез карарлар, гамәлләр (гамәл кылмау) ;

норматив хокукый актларны куллану практикасы булу;

норматив хокукый актларны кулланунын бердәм практикасы булмау;

муниципаль актны аңлату мәсьәләләре буенча гаризаларның булуы (саны) һәм эчтәлеге;

муниципаль акт белән җайга салынган мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүчеләрнең таләпләрен канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турында закон көченә кергән суд актларының булуы (саны) һәм аларны кабул итү нигезләре.

13. Федераль һәм республика законнарындагы үзгәрешләрне мониторинглау нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль актларга үзгәрешләр кертү кирәклеге ачыкланган очракта:

муниципаль актка үзгәрешләр кертү турында, муниципаль актның үз көчен югалтуын тану турында, яңа муниципаль актны кабул итү турында тиешле муниципаль акт проектлары эшләнә;

муниципаль актларны зуррак юридик көч актларына туры китерүгә юнәлтелгән башка чаралар күрелә.

14. Федераль һәм республика законнары актларына муниципаль актларга үзгәрешләр кертү зарурлыгына китерә торган үзгәрешләр кертелгән очракта, мониторинг федераль яки республика акты чыкканнан соң 30 көн эчендә үткәрелә.

Мониторинг үткәрүгә гражданнар, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, дәүләт хакимияте органнары, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының мөрәҗәгатьләре, шулай ук прокуратура мәгълүматы, «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» Федераль законда билгеләнгән вакыт эчендә карала торган прокурор җавабы актларыннан тыш, мониторинг алар кергән көннән алып 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән очракларда мониторинг үткәрү нәтиҗәләре мөрәҗәгать итүче затка хәбәр ителә.

Федераль һәм республика законнары актларына ерак перспективада үзгәрешләр кертелгән очракта, җирле үзидарә органнарының норма чыгару эшчәнлеге планнарына тиешле төзәтмәләр кертү турында тәкъдимнәр кертелә.

## III. Мониторинг нәтиҗәләрен тормышка ашыру

15. Муниципаль акт проектын эшләү һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль акт кабул итү федераль һәм (яки) республика законнарының тиешле акты үзгәргәннән соң, әлеге нигезләмәнең 14 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш, ике айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

16. Мониторинг уздыру өчен җаваплы затлар хисаптан соң килгән айның 5 числосыннан да соңга калмыйча җирле үзидарә органнары җитәкчеләре алдында ай саен мониторинг нәтиҗәләре турында хисап бирәләр.

16.1. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (мәгълүмат) түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

мониторинг уздыру объекты турында мәгълүмат;

мониторинг уздыручылар у турында мәгълүмат;

мониторинг уздыру чоры турында мәгълүмат;

хокукый җайга салу предметының кыскача характеристикасы, мониторинг

уздыру нигезләре.

16.2. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (мәгълүмат) түбәндәгеләрне үз эченә алырга мөмкин:

хокукый җайга салуның ачыкланган проблемалары турында мәгълүмат;

муниципаль актларга үзгәрешләр кертү һәм (яки) яңа актлар кабул итү, муниципаль актларны юкка чыгару зарурлыгы турында тәкъдимнәр;

тиешле хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә хокукый җайга салуны камилләштерүгә юнәлдерелгән , мониторинг нәтиҗәләренә нигезләнгән башка нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр.

17. Мониторинг нәтиҗәләре буенча яңа кабул ителгән муниципаль актлар Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда җибәрелә.

Күрсәтелгән регистрга кертү өчен мониторинг нәтиҗәләре буенча ачыкланган, анда булмаган муниципаль актлар җибәрелә.

18. Мониторинг нәтиҗәләре буенча нормалар иҗат итү процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләнергә мөмкин.

## IV. Җаваплылык

19. Мониторинг уздыру һәм хокукый эшчәнлек өчен җаваплы затлар мониторингны оештыру, шулай ук җирле үзидарә органнары карамагына карый торган муниципаль актларны үз вакытында тиешле хокукый җайга салу өлкәсендә федераль һәм республика законнарына туры китерү өчен шәхси (шул исәптән дисциплинар) җаваплылык тоталар.

20. Мониторинг йомгаклары буенча тискәре нәтиҗәләргә китергән гамәлләр кылу (гамәл кылмау), шул исәптән гражданнарга, юридик затларга, җәмгыятькә һәм дәүләткә зыян китергән өчен закон нигезендә җирле үзидарә органнары җитәкчеләре җаваплы.